*үрмәләмәкче була диген, нахал! Кичә генә бәбәй тапкан юлбарысның гайбәтен сатканнар: арысланнан микән, әллә ак барстан микән? Куркак яманаты чыккан куянга да өлеш чыккан: беркөн генә, бераз төшереп алып, төлкене куып йөргән, имеш...»* (1, б. 84)

«Ташбакачылык» памфлеты *сыныкка сылтау тапкан, коты ботка җитмәс, хет лопни, хет тресни, кояш күрде – ай алды, нахал, нәгъләт, әкренгәрәй, туйдан соң – дөмбергә калуы, йөрәгенә май булып ятты, сүз боткасы кайнату, боткасы пешмәде, майлы калҗа, эт – эткә, эт – койрыкка, астына су керә башлагач, шайтан таягы, ашыккан – ашка пешкән, иртәгесен ишәк кайгырткан, простой смертный, каһәр суккыры* кебек фразеологик гыйбарәләргә аеруча бай.

Шулай итеп, Флорид Әгъзамов 90 еллар татар матбугатында, аерым алганда, «Мәгърифәт» газетасында басылган фельетоннары һәм памфлетлары аша үзен сатира остасы итеп танытты.

**Әдәбият**

1. Флорид Әгъзамов: осталар остазы / төзүче В.З. Гарифуллин. Казан: Казан ун-ты, 2011. 155 б.

2. Гарифуллин В.З. Каләм көче (Татар журналистларының текст төзү осталыгы): Икенче китап. Казан: Казан ун-ты, 2011. 160 б.

# МЕДИАТЕКСТ В ТАТАРОЯЗЫЧНОМ РАДИО

**Р.А. Шигабутдинова,**
студент
Казанский (Приволжский) федеральный университет (Россия)
E-mail: shigab-regina09@yandex.ru
Научный руководитель: кандидат филологических наук, доцент **Л.Р.Сабирова**

**Аннотация.** Мы видим мир глазами сотрудников медиаиндустрии, и именно от них зависит то, как аудитория будет воспринимать и интерпретировать важнейшие события в стране и за рубежом. Всестороннее изучение медиатекстов важная и актуальная задача. В данной статье автор остановил свое внимание на специфике медиатекста в татароязычных радиостанциях.

**Ключевые слова:** медиатекст, радио, татарская журналистика.

**Summary :** We see the world with the eyes of the employees of the media industry, and it depends on them how the audience will perceive and interpret the major events in the country and abroad. Comprehensive study of media texts is an important and urgent task. In this article the author deals with the specifics of mediatext in the Tatar-speaking radio stations.

**Keywords:** media, radio, Tatar journalism.

# ТАТАР РАДИОСЫНДА МЕДИАТЕКСТ

Татар матбугатындагы медиатекст барлык массакүләм мәгълүмат чараларына карый. Медиатекстны матбугат чарасының һәрбер материалы буларак түгел, ә таррак мәгънәсендә – берничә форматтагы мәгълүмат йөртүче чыганакларның катнаш системасы буларак тулы бер эш итеп карыйк [1].

Материал әзерләгәндә, журналистлар эфирда яңгыраган текстка карата төгәл, ачык, кыска, кызык, хатасыз төшенчәләрне чагылдырган сыйфатларны исәпкә ала. Бу очракта сөйләм интонациясе мөһим роль уйный.

Радионың мөмкинлекләре чикләнгән булу сәбәпле, озак вакытлы бертөрле сөйләм тиз ялыктыра. Шуңа күрә текстның күләмен исәпләп, аны дөресләп, барлык артык сүзләрне алып ташлап, бары тик әһәмиятле булган, аудитория белгәненнән тыш, өстәмә төп яңалыкны гына җиткерергә кирәк.

Исемнәрне тулысынча әйтеп бирү, шәхесләрнең вазифаларын яисә һөнәри билгеләнешләрен кыска һәм гомум кабул ителгән формада куллану, кеше әйткән сүзне «цитата», «цитата китерәм» сүзе белән һ.б. инде гадәти кагыйдәләрдән санала. Билгеле, ситуациясенә карап, бүгенге көндә алар еш кына бозыла.

Радиода барлык фонетик элементлар – тавыш, яңгыраган сөйләм, музыка, шау-шу һәм интертавыш – композицион берлектә була, бер-берсенә булышлык итә, тулыландыра.

Күренекле Канада социологы Маршал Макклюэн узган гасырның 60нчы елларында ук медиамәдәният текстын һәрвакыт актуаль бер җөмлә белән әйтеп бирә: the medium is the message – канал – ул хәбәр. Һәм бу хәбәр характеры кайсы массакүләм мәгълүмат чарасы өчен барлыкка китерелгән булса, шуның техник мөминлекләреннән чыгып билгеләнә [1].

Радиога килгәндә, анда махсус төзелгән радиотекстларда яңгыраучы сөйләм һәм музыкаль озатылыш мөмкинлеге киң кулланыла. Үз кысаларында эш итү мөмкинлекләреннән чыгып, монда да медиатекстка урын табылган. Радиоэфир вакытында алып баручы яки әңгәмәдәшнең сөйләме генә түгел, музыка мөмкинлекләре дә файдаланыла. Мондый ысул бигрәк тә реклам белән бәйле медиатекстларда чагылыш тапкан.

Радиодагы медиатекстны шартлы рәвештә ике төргә бүлергә була:

1. **Текст + фон буларак музыка (лат. txt-background).**

*«Тормыш – тамаша», аннан күзләр камаша. «Күңел» җырчы йолдызларга сорау өләшә, ә син җавабын тыңла* (фонда көй; «Күңел» радиосыннан).

2. **Текст + юлдашчы музыка (медиатекстта турыдан-туры катнаша (лат. txt-accompaniment).**

*(ир-ат тавышы): Тулы исеме. (фонда – төймәгә баскан тавыш)*

*(хатын-кыз тавышы): Наил Нахис улы Әзгамов (төймә тавышы)*

*И.Т.: Туган җире (төймә тавышы)*

*Х.Т.: Актаныш районы Иске Кормаш авылы.*

*И.Т.: Туган елы.*

*Х.Т.: 1975 ел.*

*И.Т.: Туган көне.*

*Х.Т.: 2 август.*

*И.Т.: Яратмаган ризыгы.*

*Х.Т.: Окрошка. (төймә тавышы ахыргача дәвам итә, җырлардан өзекләр китә)»* («Күңел» радиосыннан).

Катнашучылар санынннан чыгып, медиатекстларны болай бүләбез:

1. **Монолог**. Алып баручы яки чакырылган кунак үзе генә сөйли, сөйләме фонында музыка яңгырый, озынрак паузалар вакытында бераз көчәя. Күбрәк текст төзелеше һәм уку интонациясе йогынты ясый. *(«Татарстан» радиосының «Татарстан дулкынында» программасы)* [2].

2. **Диалог яки полилог**. Студиядә берничә кеше әңгәмә кора. Темасына карап, музыка сайлана, кайбер мизгелләрдә ул бөтенләй басыла. Мондый типтагы эфирлар гадәттә импровизацион рәвештә уза, алар күпкә кызыклырак. *(«Болгар» радиосындагы «Чәк-чәк шоу» һәм «Шөпшә шоу» тапшырулары)* [2].

Медиалингвистика кысаларында яңалыклар, мәгълүмати-аналитик, features һәм рекламаны аерып карау аеруча әһәмиятле мәгънәгә ия.

Алар хәбәр белән йогынты төшенчәләре арасында түбәндәгечә урнаша:

**Яңалыклар – Мәгълүмати-аналитик – Features – Реклама**

Татарстан Республикасында иң популяр радиостанцияләр – ул «Татарстан», «Болгар», «Татар радиосы», «Тәртип», «Курай» һәм «Күңел». Бирелгән типологиягә туры китереп, әлеге радиоканаллар мисалында татар радиосындагы медиатекст чагылышын карап китик.

Радио хәбәрләре текстлары ике төр программада тәкъдим ителсә, татар радиосында аның беренче – кыска вакытлы хәбәрләр бүлеге генә эшли. Бу күп булса, биш минутлык, һәр сәгать башында трансляцияләнгән **яңалыклар** белешмәсе. Гадәттә, кыска яңалыклар чыгарылышы бер генә алып баручы тарафыннан укыла һәм яңалык текстыннан тора, тотырыклы схема буенча 5-6 хәбәрдән торган яңалык тексты конкрет радиоканалның шартларыннан чыгып төрләнергә мөмкин. Барлык татар радиоканалларында соңгы сәгатьтәге мөһим яңалыкларны җиткереп баралар. Бары тик «Болгар» радиосында гына аларны темасы ягыннан төрле өлкәләргә бүләләр (сәясәт, спорт һ.б.).

*«Бу минутларда Казанда 1 градус салкын. Валюталар курсына килгәндә, доллар 66 сум 6 тиен, евро 74 сум 70 тиен. Артур Фәләхов. Яңалыклар хезмәте».* («Болгар» радиосыннан).

Радио һәм телевидениедә **мәгълүмати-аналитик** текстлар фактлар һәм комментарийларны берләштергән тапшыруларда бирелә. Мондый тапшыруларны сәясәтчеләр, эшмәкәрләр, хәрбиләр һәм башка информацион процесста катнашучылар дөньяда барган хәл-вакыйгаларга күзәтү, белгечләр комментарийлары, экспертлар фикере белән тәэмин итә. Дөресен әйткәндә, татар радиосында аналитика юк дәрәҗәсендә диярлек. Бу, беренчедән, аналитик

фикерләүгә сәләтле кадрлар һәм, аннан яманы, аудиториянең радио аша бирелгән аналитикага ихтыяҗы булмауда.

Радиожурналистикадагы мәгълүмати-аналитик тапшыру итеп *«Татар радиосы»ндагы Гөлназ Сәфәрованың «Туры эфир» авторлык тапшыруын* әйтергә була. Бу алып баручы программаларына белгечләрне җәлеп итү ягын карый. Мәсәлән, тапшыруларының берсенә аның кунагы булып *юрист, «Куб» юридик агентлык җитәкчесе Марат Хәлимов килгән. Эфир барышында ипотека, фатир приватизацияләү, арендага алу мәсьәләләре күтәрелә.*

Электрон массакүләм мәгълүмат чараларында публицистиканың чикләре бик үк төгәл билгеләнмәгән, ләкин **feature** материалларының формат тотрыклылыгы, тематик бәйләнеше һәм тел экспрессивлыгы саклана. Йогынты ягыннан иң көчле форматның берсе саналса да, татар радиосында әлеге форматтагы барлык тапшыруларның йогынтысы югары дәрәҗәдә түгел. Киресенчә, кайберләре бер тонлы һәм игътибар җәлеп итми.

*Мәсәлән, «Тәртип» радиосында күбесенчә татар халык җырлары, сирәк очрый торган язмалар, югалып барган җырлар, халык җәүһәрләре эфирда яңгырый. Алар радио директоры Марат Ибләминовның 10 ел җыйган 7 меңләп җырдан торган архивыннан алынган. Ни кызганыч, аларны тәкъдим иткән тапшыруларда бүгенге көндә ихтыяҗ юк диярлек.*

*«Болгар» радиосындагы «Уңыш формуласы» тапшыруын да радиостанциянең абруе һәм алып баручыларның тел шомалыгы гына коткара.*

**Реклама** текстларының специфик үзенчәлекләре – ул ачыктан-ачык йогынты ясауга юнәлдерелгәнлеге. Радионың эффектлылыгына ике яклы йогынтылыкта: телдән әйтелгән текст һәм музыкаль яктан бизәлеш алган тавыш тиңдәшлеге нәтиҗәсендә ирешергә була.

*«Болгар» радиосына 3 ел! 13 март, Филармония залы. Безнекеләр җырлый! (радионың алып баручылары башкаруында җыр өзекләре) Безнекеләр сөйли! (Айгөл Хәйруллина башкаруында шигырь өзеге, фонда колакка ятышлы музыка) Безнекеләр шаярта! (Рөстәм Гайзуллин опера тавышын чыгарырга тырышып, мәзәк җырлый, фонда тынлык, рок стилендә музыка кушыла) 13 март, Филармония залы. «Болгар» радиосына 3 ел! Билетлар сатуда».* («Болгар» радиосыннан).

**Реклама-диалог** та радио һәм телевидениедә уңышлы кулланыла һәм реклама текстын төзүчеләргә үзләренең оригинальлеге һәм үткен сүзлегендә чикләнмәгән күләмдә мөмкинлекләр ача.

*«(Әкрен, хисле көй уйный) 1нче тавыш: «Кайчагында ымсындыргыч күккә карыйсың да, хыялларга биреләсең. Син канатлы, син очасың, син тормыштан канәгать! Син – яхшы кәеф патшасы! За-а-амечательны... Күзеңне ачасың да, чынбарлыкка кайтасың...» (тизрәк, шаян музыка кушыла) 2нче тавыш: «Әмма чынбарлык хәзер шулай ук күңелле! Чөнки «Болгар» радиосында «Шөпшә шоу» радиотамашасы бар. Һәр якшәмбе кичке 7дән төнге 12гә кадәр»* («Болгар» радиосыннан).

Инглиз-америка җирлегендә барлыкка килгән популяр радио һәм телеформатлар үзгәртеп-кору чорындагы Россиядә уңышлы кулланыла башлаган. Инглиз телемассмедиа форматы базасындагы күп тапшырулар talk-show (ток-шок), quiz (викториналар), phone-in programme (программада телефон), реалити-шоу, confession radio (радио-тәүбә итү) һ.б. Татарстанда да үсеш ала бара [3]. Ә менә сораштырулар һәм тикшеренүләргә караганда, гомумән, бүгенге көндә радио белән телевидениега ихтыяҗ кимегән, күбрәк газета, инфографика, фотосурәт, интернетка карыйлар [3].

Мәгълүмат технологиясе үсеше перспективаларын һәм республиканың информацион куркынычсызлыгын бәяләп, түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин:

– татар радиосының ил һәм дөньякүләм каналлардан аермалы төп үзенчәлеге – ул милли төсмер (халык әйтемнәрен, менталитетка хас сөйләм телен куллану һ.б.);

– татар радиосында медиатекст, формасына һәм катнашучыларга карап, икешәр төргә бүленә: форма буенча – текст-background һәм текст-accompaniment, катнашучылар санына карап – монолог һәм диалог/полилог;

– татар радиосында медиатекст үз чагылышын ешрак рекламада һәм туры эфирда барган, яртылаш импровизацион рәвештә барган күңел ачу тапшыруларында таба.

**Әдәбият**

1. Добросклонская Т.Г. Мы видим мир глазами многочисленной армии сотрудников медиаиндустрии // Журнал «МедиаТренды». Факультет журналистики МГУ им. Ломоносова. №6 (48), 28 ноября, 2014. С.4. URL: http://www.mediascope.ru/files/MediaTrendi_48%20(2).pdf

2. Добросклонская Т.Г. Медиалингвистика: системный подход к изучению СМИ. М. 2008. [Электронный ресурс]/ URL: http://www.ffl.msu.ru/research/publications/dobrosklonskaya/dobrosklonskaya-medialingvistika.pdf (дата обращения: 22.03.2016).

3. Корконосенко С.Г. Социология журналистики: учебное пособие для студентов вузов. М.: Аспект Пресс, 2004. С. 90-108.